**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«20» 10 2023 ел Яр Чаллы ш. № 3522

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ромашка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ромашка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Ромашка» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 ноябрендәге 3554 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Муниципаль район Башкарма комитетының 2023 елның «20» 10 3522 номерлы карарына 1 кушымта

2023 елның 1 октябреннән ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ромашка» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Кызыклы инглиз теле» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Оста куллар» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Читай-ка» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Хореография» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 5 | «Тавышлы уен кораллары оркестры» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 6 | «Шахмат» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 7 | «Менталь арифметика» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Ромашка» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Кызыклы инглиз теле»** - программа сөйләм күнекмәләрен үстерүгә, тел мохитенә чумуга һәм чит телне өйрәнүгә кызыксыну уятуга юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (2 төркем - 30 тәрбияләнүче).

2. **«Оста куллар»**- эре һәм вак моториканы үстерүгә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (3 төркем - 45 тәрбияләнүче).

3. **«Читай-ка» -** балаларны мәктәпкә әзерләү (сөйләм үстерү, грамотага өйрәтү). Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (2 төркем - 40 тәрбияләнүче).

4. **«Хореография»**- пластика, ритм хисе, физик үсеш, киңлектә ориентация үсешенә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (2 төркем - 30 тәрбияләнүче).

5. **«Тавышлы уен кораллары оркестры»**- балалар музыка коралларында уйнау осталыгына кызыксыну уятуга, иҗади сәләтләрне үстерүгә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (14 тәрбияләнүче).

6. **«Шахмат»**- логик һәм математик фикерләүне, спорт-танып белү юнәлешен үстерүгә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (2 төркем - 25 тәрбияләнүче).

7. **«Менталь арифметика»**- логик һәм математик фикерләүне, спорт-танып белү юнәлешен үстерүгә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (2 төркем - 38 тәрбияләнүче).